**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 сентябрь № 679

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 май, 327 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 май, 327 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 май, 300 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

уникенче – унбишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балаларны сәламәтлекләренә һәм үсешләренә зыян китерүче мәгълүматтан саклау турында» 2010 ел, 29 декабрь, ФЗ-436 нчы Федераль Закон»;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 ел, 19 октябрь, б-1683 боерыгы;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация

белешмәлеген, «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация сыйфатламалары» бүлеген раслау хакында» 2011 ел, 30 март, 251н боерыгы;

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Китапханәләр фонды составына кергән документларны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2012 ел, 8 октябрь, 1077 нче боерыгы;»;

текстка түбәндәге эчтәлекле унсигезенче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Китапханәләрдә башкарыла торган эшләргә үрнәк тармак хезмәт нормаларын раслау турында» 2014 ел, 30 декабрь, 2477 нче боерыгы;»;

6.2 нче пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының «Россия Федерациясендә Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында (ЯКК 01-03)» 2003 ел, 18 июнь, 313 нче боерыгы белән расланган Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 ел, 25 апрель, 390 нчы карары белән расланган Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә» сүзләренә алмаштырырга;

XII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«XII. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын сакламауга шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын сакламауга шикаять (алга таба – шикаять) дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмага язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарга шикаять югарыдагы органга (дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманы гамәлгә куючыга) бирелә.

12.2. Шикаять почтадан, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың рәсми сайтын, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын кулланып җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүче шәхсән тапшырганда кабул ителә ала.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

12.4. Шикаять тапшырылган көнне теркәлергә тиеш һәм теркәлгән көннән соң 15 эш көне эчендә шикаятьләрне карау вәкаләтләре йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан карап тикшерелергә тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма, дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга шикаять биргән очракта яисә әлеге төзәтмәләргә куелган вакытны бозуга шикаять биргән очракта – теркәлгәннән соң 5 эш көне эчендә.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм, аны кабул иткән көннән соң килүче көннән

дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында язмача һәм гариза бирүче теләге буенча – электрон формада дәлилләнгән җавап җибәрә.

12.6. Граждан (аның законлы вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирә ала.

12.7. Гражданнарны дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмада кабул итү аның җитәкчесе һәм әлеге вәкаләтләр тапшырылган затлар тарафыннан үткәрелә. Кабул итү урыны турында, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр хакында мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма бинасындагы мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\679.docx